РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 40

27 сентябрь, 2018 ел

**Түбән Кама шәһәренең төзелеш һәм җирдән файдалану Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 маддәләре, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре Уставы нигезендә, күчемсез милек хокукына ия затларның һәм күчемсез милек объектларыннан файдалану, файдалану хокукларын сатып алырга теләгән затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатларында, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1.Түбән Кама шәһәр Советының 2010 елның 22 декабрендәге 20 номерлы карары белән расланган, Түбән Кама шәһәренең төзелеш һәм җирдән файдалану Кагыйдәләренең картографик материалларына үзгәрешләр кертергә (1нче кушымта).

2.Түбән Кама шәһәр Советының 2010 елның 22 декабрендәге 20 номерлы карары белән расланган, Түбән Кама шәһәренең төзелеш һәм җирдән файдалану Кагыйдәләренең текст материалларына үзгәрешләр кертергә (2нче кушымта).

4.Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында һәм басма матбугатта бастырып чыгарырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

2нче кушымта
40нчы номерлы
Түбән Кама шәһәр Советы карарына
27 сентябрь, 2018 ел

**Түбән Кама шәһәренең төзелеш һәм җирдән файдалану**
**Кагыйдәләренә кертелә торган**
**үзгәрешләр**

Керешнең 1 абзацындагы «(Алга таба -Түбән Кама муниципаль районы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 маддә. Әлеге Кагыйдәләрдә кулланыла торган төшенчәләр.

Әлеге Кагыйдәләрдә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы белән билгеләнгән төшенчәләр кулланыла.»;

4 маддәнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Шәһәр төзелеше регламентында тиешле территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына карата, күрсәтелә:

1) җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән куллану төрләре;

2) җир кишәрлекләренең чик (минималь һәм (яки) максималь) күләме һәм рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрлары;

3) Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын куллануны чикләү;

4) территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителүнең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәдә исәп-хисап күрсәткечләре һәм шәһәр төзелеше регламенты билгели торган территориаль зона чикләрендә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру күздә тотылса, күрсәтелгән объектларның халыкка территориаль яктан мөмкин булган максималь дәрәҗәдә үтемлелеге исәп-хисап күрсәткечләре.

Расланган Кагыйдәләр Россия Федерациясе Һава кодексы нигезендә билгеләнгән, аның чикләрендә тулысынча яки өлешчә урнашкан аэродром яны территориясе, аэродром яны территориясендә билгеләнгән җир кишәрлекләрен һәм (яки) аларда урнашкан күчемсез милек объектларын куллануны һәм икътисадый һәм башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашыруны чикләүгә каршы килә торган өлешендә кулланылмый.»;

7 маддәнең 1 пунктындагы «(2008 елның 30 декабрендәге 149-ТРЗ номерлы ТР Законы белән кертелгән үзгәрешләр белән) » сүзләрен төшереп калдырырга;

10 маддәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.Гамәлдәге законнарда һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә Комиссия:

- гавами тыңлаулар үткәрүне оештыра;
- җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү мәсьәләләрен карый;
- Түбән Кама шәһәре Мэрына Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү яки үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне кире кагу турында тәкъдимнәр әзерли;

- әлеге кагыйдәләрне гамәлгә ашыру һәм куллануга бәйле норматив хокукый актлар, башка документлар проектларын әзерләүне оештыра;

- кирәкле мәгълүматны соратып ала;

- башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.».

10 маддәне түбәндәге эчтәлекле 4 пункт белән тулыландырырга:

«4. Әлеге кагыйдәләрне аэродром яны территориясендә билгеләнгән күчемсез милек объектларын куллануны чикләү белән тәңгәлләштерүне күздә тоткан Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турындагы Проект комиссия тарафыннан карап тикшерелергә тиеш түгел.»;

11 маддәнең 4 пунктында «әлеге Кагыйдәләрнең 12 маддәсе белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

14 маддәнең 1 пункты 2 пунктчасындагы «44 маддәнең 3 һәм 4 кисәкләре белән» сүзләрен «57.3 маддәсе белән» сүзләренә алмаштырырга;

7 маддәнең 3 пунктын, 3 пунктның 1,2 пунктчаларын, 15 маддәнең 4 пунктын, 17 маддәнең 1 пунктындагы 2 абзацын төшереп калдырырга;

19 маддәнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге Кагыйдәләргә үзгәрешләр проектын әзерләү турындагы карар Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан карар рәвешендә кабул ителә, ә бу вәкаләтләр бирелгән очракта, карар әлеге вәкаләтләр бирелгән Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органы тарафыннан кабул ителә.

Башкарма комитет җитәкчесе әлеге Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне карау өчен нигез булып тора:

- мондый генераль планнарга яки муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җирлекнең генераль планы, муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасы кагыйдәләренең туры килмәве;

- Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән башкарма хакимиятнең федераль органыннан, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда үтәү өчен, Кагыйдәләргә кертелгән аэродром яны территориясендә билгеләнгән күчемсез милек объектларын куллануны чикләүне бетерү турында күрсәтмәләр керү;

- территориаль зоналар чикләрен үзгәртү, шәһәр төзелеше регламентларын үзгәртү турында тәкъдимнәр керү.»;

19 маддәнең 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 28 маддәләре, 31 маддәсендәге 13,14 кисәкләре нигезендә Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы һәм (яки) Түбән Кама шәһәр Советының муниципаль хокукый акты белән билгеләнә торган тәртиптә Комиссия тарафыннан уздырыла. Җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен аэродром яны территориясендә билгеләнгән күчемсез милек объектларын куллануны чикләү белән тәңгәлләштерү очрагында җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар үткәрелми»;

19 маддәнең 12 пунктын «конкрет территориаль зона өчен билгеләнгән шәһәр төзелеше регламентына үзгәрешләр кертү өлешендә Кагыйдәләргә үзгәрешләр әзерләнгән очракта, җәмәгать фикер алышулар яисә кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү буенча гавами тыңлаулар аның өчен мондый шәһәр төзелеше регламенты билгеләнгән территориаль зона чикләрендә үткәрелә. Бу очракларда җәмәгать фикер алышуларын яки гавами тыңлауларны үткәрү вакыты бер айдан артык булырга тиеш түгел.» сүзләре белән тулыландырырга;

19 маддәнең 14 пунктында «вәкаләтле орган белән килештерү турында нәтиҗә» сүзләреннән соң («законда билгеләнгән очракларда») сүзләре белән тулыландырырга;

19 мадданең 17 пунктында «күрсәтелгән проект буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре нигезендә» сүзләрен «әлеге проект буенча җәмәгать фикер алышуы яки гавами тыңлаулар нәтиҗәләре нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

21 мадданең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Шәһәр төзелеше зоналаштыру картасында җирлек составына керүче торак пунктларның чикләре, территорияләрне аерым куллану шартлары булган зоналар чикләре, мәдәни мирас объектлары территорияләренең чикләре, федераль әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләре, региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләре мәҗбүри рәвештә күрсәтелә. Күрсәтелгән чикләрне аерым карталарда күрсәтергә мөмкин.

Шәһәр төзелеше зоналаштыру картасында мәҗбүри тәртиптә, алар чикләрендә мондый эшчәнлекне планлаштыру очрагында, территорияне комплексны һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру күздә тотылган территория билгеләнә. Мондый территорияләрнең чикләре бер яки берничә территориаль зона чикләре буенча билгеләнә һәм аерым картада күренергә мөмкин.»;

8 маддәдә, 9 мадданең 1 пунктында «Түбән Кама шәһәре Советы» сүзләрен «Түбән Кама шәһәр Советы» сүзләренә алмаштырырга;

19 мадданең 15,17 пунктларында «Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Советы» сүзләрен «Түбән Кама шәһәр Советы» сүзләренә алмаштырырга»;

19 мадданең 15 пунктында «Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Советы» сүзләрен «Түбән Кама шәһәр Советы» сүзләренә алмаштырырга»;

19 мадданең 11,16 пунктларында «Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Советы» сүзләрен «Түбән Кама шәһәр Советы» сүзләренә алмаштырырга»;

23 маддәдә «Түбән Кама шәһәре Советы» сүзләрен «Түбән Кама шәһәр Советы» сүзләренә алмаштырырга;

17 мадданең 5 пунктында, 19 мадданең 10 пунктында «Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы» сүзләрен «Түбән Кама шәһәре Мэры» сүзләренә алмаштырырга;

19 мадданең 9 пунктында «Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы» сүзләрен «Түбән Кама шәһәре Мэры» сүзләренә алмаштырырга;

2 мадданең 2, 3 пунктларында, 10 мадданең 3 пунктында, 16 мадданең 2 пунктында, 19 мадданең 10, 12-17 пунктларында «гавами тыңлаулар» сүзләрен «җәмәгать фикер алышуы яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга;

5 мадданең 5 пунктында, 19 мадданең 13 пунктында «гавами тыңлаулар» сүзләрен «җәмәгать фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда» сүзләренә алмаштырырга;

19 мадданең 11,13 пунктында «гавами тыңлаулар» сүзләрен «җәмәгать фикер алышуы яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга.

Түбән Кама шәһәренең Җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең Д-1 территориаль зонасын өстәмә куллану төрләре «мобиль автомобиль юу (капиталь булмаган)» рөхсәт ителгән өстәмә куллану төрләре исемлегенә кертергә.

Түбән Кама шәһәре Мэры
урынбасары Э.Р. Долотказина